ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.08.2024 ел Баулы шәһәре №111

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы карары белән расланган, җир кишәрлеген бирүне алдан килештереп, муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 31 мартындагы 85 номерлы, 2024 елның 8 февралендәге 10 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы карары белән расланган, җир кишәрлеген бирүне алдан килештереп, муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 31 мартындагы 85 номерлы, 2024 елның 8 февралендәге 10 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлектә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты»:

2.8.3.2.пунктында:

8) пунктчада «территорияне комплекслы үстерү» сүзләреннән соң «яки күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителде» сүзләре белән тулыландырырга;

9) пунктчада «территорияләр, яки» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү турында карар йә күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, яисә» сүзләре белән алмаштырырга;

10) пунктчада «территорияләр, һәм» сүзләрен «күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, яки аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, һәм» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров